| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет Абалачевского сельского<br>поселения Менделеевского<br>муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Абалач авыл җирлеге Советы |

| | |
|---|---|
| Р Е Ш Е Н И Е<br>2021 елның 24 мартыннан | К А Р А Р<br>№ 28 |

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районының
«Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү буенча карар проекты турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Абалач авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Советы,

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 24 маендагы 79 номерлы Абалач авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналары.» 35 статьяның «Шәһәр төзелеше зонасы картасында билгеләнгән территориаль зоналар төрләре» бүлегендә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв.м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең максималь күләме - 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.».

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Советы Карары проектын карау буенча 2021 елның 24 апрелендә 11 сәгать 00 минутта түбәндәге адрес буенча ачык тыңлаулар үткәрергә: Татарстан Республикасы, Абалач авыл җирлеге, Абалач авылы Үзәк ур., 35 йорт, Татарстан

Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге мәдәният йорты бинасының актлар залы.

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү комиссиясе составын кушымта нигезендә расларга.

4. Комиссиягә югарыда күрсәтелгән проектның демонстратив материаллары экспозициясен «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Советы карары проекты белән таныштырырга, кызыксынган затларның искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен түбәндәге адрес буенча кабул итәргә: Татарстан Республикасы, Абалач авыл җирлеге, Абалач авылы, Үзәк ур., 35 йорт, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге мәдәният йорты бинасының актлар залы;

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Абалач авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru/ «Абалач авыл җирлеге» бүлегендә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Рәис урынбасары Л.А. Шияпова

Кушымта
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Абалач авыл җирлеге
Советының
2021 елның 24 мартындагы
28 нче номерлы карарына

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" карары проекты буенча ачык тыңлаулар барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча комиссия составы

1. Комиссия рәисе урынбасары: Шияпова Ландыш Альберт кызы - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Советы Рәисе урынбасары;
2. Комиссия әгъзасы: Низаметдинова Анастасия Герасимовна-Абалач авыл җирлеге Советы депутаты;
3. Комиссия әгъзасы: Насыйбуллин Айрат Әсхәт улы – Абалач авыл җирлеге Советы депутаты;
4. Комиссия әгъзасы: Шаихов Илдар Шәйхенур улы - Абалач авыл мәктәбе директоры;
5. Комиссия әгъзасы: Хәбиров Равил Зөфәр улы – Менделеевск муниципаль районы инвестицион һәм инфраструктура үсеше идарәсенең проектлау бүлеге башлыгы.